**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлеге Урта Камышлы торак пунктында гражданнар җыены КАРАРЫ**

**27 октябрь 2025 ел** **№ 8**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Урта Камышлы авыл җирлеге Урта Камышлы авылы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ**:**

1.Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Урта Камышлы авыл җирлегенең Урта Камышлы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2025 елда үзара салымны 1000 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә :

- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- Су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- Урамнарны яктырту җайланмасы.

Халык җыенында рәислек итүче: В.П. Вафина

Урта Камышлы авыл җирлеге башлыгы В.П. Вафина